СОВЕТ МАЛОМЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛ РАЙОНЫ КЕЧЕ МӘМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 30 нчы сентябере Кече Мәми авылы № 27

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Малалла авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2019 елның 23 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Малалла авылы, Коммуны урамы, №12 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең Малалла авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Кече Мәми авыл җирлеге Малалла авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

а) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Кече Мәми авыл җирлеге башлыгы Е.Н. Алексеева